**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ЖУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЖУКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422382 д. Жуково, ул.Верхняя, 8

422382 Жуково авылы, Югары ур, 8

тел. (84373) 5-32-22, факс 5-32-22, e-mail guk.tet@tatar.ru
ОГРН 1061672018286 , ИНН/КПП 1638005033/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**06.12.2024** **№ 16**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Жуково авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 3 августындагы 19 номерлы «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында " 05.02.2024 ел, № 124 карары нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Жуково авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:
1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Жуково авыл җирлеге Башкарма комитетының 03.08.2021 № 19 карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1) 1.2 пунктның 10 абзацында " әлеге пунктта күрсәтелгән зат исеменнән» сүзләрен «гаризасы белән»сүзләренә алмаштырырга.;
2) 1.5 пунктның 10 абзацында "(шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), " сүзләреннән соң "яр буе,»сүзен өстәргә.;
3) 1.5 пунктның 11 абзацында «яр буе," сүзен төшереп калдырырга;
4) 2.3.2 пунктта «берләштерелергә мөмкин» сүзләрен «берләштерелә»сүзенә алмаштырырга;
5) 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2.4. Адреслашу объектына адрес бирү яисә аның адресын юкка чыгару турында Карар кабул итү, адреслашу объектына адрес бирүдән баш тарту яисә аның адресын юкка чыгару турында карарлар, шулай ук адреслашу объектының адресы турында тиешле белешмәләрне дәүләт адреслар реестрында урнаштыру Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла:
а) гариза кәгазьдә бирелгән очракта-гариза кергән көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча;
б) электрон документ рәвешендә гариза биргән очракта - гариза кергән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча.»;
6) 2.4.1 пунктын төшереп калдырырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **Н.А. Борисова**